Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең
Иске Борындык авылында гражданнар җыены карары

03 ноябрь 2025 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Чуаш Сарыкамышы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Боерган авыл җирлегенең Чуаш Сарыкамышы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау) ;

- Чуаш Сарыкамышы авылында торак пункт территориясен төзекләндерүгә ( кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эш һәм килешү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Боерган авыл җирлегенең Чуаш Сарыкамышы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге башлыгы _________ И.В. Малышева

Халык җыены секретаре _________ О.А. Малышева